РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**посёлка городского типа**
**КАМСКОЕ УСТЬЕ**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Кама Тамагы**
**шәһәр тибындагы поселогы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Советска, 11, пгт. Камское Устье, 422820
тел. (884377) 2-19-40, 2-15-76, факс: (884377) 2-14-76
ОКПО 78692631, ОГРН 1051651018484
ИНН/КПП 1622004531/162201001

Совет урамы, 11,Кама Тамагы штп, 422820,
тел. (884377)2-19-40, 2-15-76, факс: (884377) 2-14-76
ОКПО 78692631 ОГРН 1051651018484
ИНН/КПП 1622004531/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 30 гыйнварындагы 3 номерлы

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты КАРАР бирде**:**

1. 2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегендә , 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә, күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында»гы 2019 елның 20 мартындагы 71 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

-ТР, Кама Тамагы районы, Кама Тамагы ш.т.п., Совет ур.

- ТР, Кама Тамагы районы, Кама Тамагы ш.т.п., К.Маркс ур., 105 йорт (китапханә бинасы),

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга .

4. Әлеге карар 2020 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче И.Ф.Яруллин

Кама Тамагы
муниципаль районы Кама Тамагы
штп Башкарма комитетының
2020 елның 30 гыйнварындагы
3номерлы карарына
1 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләрнең бәясе исемлеге

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *( сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3670,18 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка илтү | 522,27 |
| 4. Җирләү (каберләр казу һәм күмү) | 1932,41 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Кама Тамагы
муниципаль районы Кама Тамагы
штп Башкарма комитетының
2020 елның 30 гыйнварындагы
3номерлы карарына
2 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләрнең бәясе исемлеге

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе-*( сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 188,35 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3481,83 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка илтү | 522,27 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1932,41 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |